Югары Чура авылы җирлеге Советы

Карар

13 ноябрь, 2019 ел №21

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авылы җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Югары Чура җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Югары Чура авылы җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авылы җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында кушып бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Югары Чура авылы җирлеге Советының «Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында»2019 елнын 17 сентябрьдэге 22 номерлы карарын көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авылы җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Югары Чура авыл җирлеге
башлыгы урынбасары: А.Н. Афанасьев

Югары Чура авылы җирлеге
Советының № 21 карарына
кушымта
13 ноябрь, 2019 ел

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль
районы Югары Чура авылы җирлеге
составына керүче торак пунктларда
гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү
тәртибе турында Нигезләмә

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авылы җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Югары Чура җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә эшләнде.

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданнар җыены гомуми, тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә үткәрелә.

1.2. Гражданнар җыенында торак пунктта яшәүчеләр, даими яки нигездә аның территориясендә яшәүчеләр, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән һәм сайлау хокукына ия кешеләр катнашырга хокуклы.

1.3. Гражданнар җыенында катнашу ихтыяри һәм ирекле.

1.4. Гражданнар җыенда шәхсән үзе катнаша, һәм аларның һәркайсы бер тавышка ия.

1.5. Гражданнар җыены турыдан-туры халык тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатыннан үткәрелә.

1.6 Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүче сайлау хокукына ия кешеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта булу мөмкинлеге булмаган очракта, Югары Чура авылы җирлеге Уставы нигезендә, гражданнар җыены этаплап уздырыла.

Гражданнар җыены вәкаләтләре

1.7. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

күрсәтелгән торак пункт аның составына керә торган, күрсәтелгән торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертүне үз эченә алган торак пунктта авыл җирлеге (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;

җирлек составына керүче торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

авыл торак пунктында авыл җирлеге старостасы кандидатурасын тәкъдим итү, шулай ук авыл җирлеге старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелергә мөмкин.

Гражданнар җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү

1.8. Җыенны үткәрү Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Югары Чура авылы җирлеге башлыгы (алга таба – җирлек башлыгы) тарафыннан тәэмин ителә.

1.9. Жыенга әзерлек һәм аны үткәрү белән бәйле чыгымнар Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авылы җирлеге бюджеты хисабына башкарыла.

2. Гражданнар җыенын чакыру тәртибе

Халык җыены үткәрү инициативасы

2.1. Халык җыенын үткәрү инициативасы – торак пунктта:

- җирлек башлыгына;

- гражданнар җыенында катнашырга хокуклы 10 кешедән ким булмаган сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләр төркеменә (ягъни, 18 яшькә җиткән даими яки нигездә торак пункт территориясендә яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән Россия Федерациясенең эшкә сәләтле гражданнары, шулай ук торак пункт территориясендә даими яки нигездә яшәүче, җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә хокукка ия булган чит ил гражданнары) карый.

2.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең инициативасы язылу кәгазе (1 нче кушымта) яисә халык җыенын үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында Карар кабул ителгән инициативалы төркем җыелышының беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелергә тиеш, анда түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләр;

гражданнар җыенын үткәрүнең тәкъдим ителгән вакыты;

халык җыенын чакыру турында инициативаны хуплаучы һәр гражданның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган көне; паспорт яки аны алмаштыручы документның сериясе һәм номеры, яшәү урыны адресы; гражданның имзасы һәм имза куелган дата.

2.3. Җыенны үткәрү инициативасын хуплау өчен җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия булган, торак пункт территориясендә даими яки нигездә яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санынннан 5 процент тәшкил итә, ләкин 10 имзадан да ким була алмый.

2.4. Язылу кәгазьләре имзалар җыючы зат тарафыннан раслау датасын, фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, туган көнен, паспорт яки аны алмаштыручы документ номерын һәм сериясен, яшәү урынын күрсәтеп раслана һәм муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.

Гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул итү тәртибе

2.5. Инициативалы төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены – Югары Чура авылы җирлеге Советы карары белән (алга таба – җирлек Советы) (2 нче кушымта), җирлек башлыгы инициативасы белән чакырылганда – җирлек башлыгы карары белән (3 нче кушымта) барлык кирәкле документлар кергән көннән соң 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Авыл җирлеге башлыгы яки җирлек Советы гражданнар җыенын үткәрүдән, аның максатка ярашсызлыгына сылтап, баш тартырга хокуклы түгел.

2.7. Гражданнар җыенына (гражданнар җыены этапларына) чыгарылган мәсьәлә Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәскә тиеш. Халык җыены мәсьәләсе аңа күптөрле аңлатма бирү мөмкинлеге калдырылмыйча формалаштырылырга тиеш, ягъни аңа берсүзсез бер генә җавап бирерлек булсын.

2.8. Гражданнар җыенын билгеләү, аны күчерү турындагы карарны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Югары Чура авылы җирлеге Уставы белән билгеләнә һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авылы җирлеге Уставында муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен каралган тәртиптә басылып чыга (халыкка җиткерелә).

Гражданнар җыенын үткәрү турындагы авыл җирлеге Башлыгы карарында яки җирлек Советы карарында түбәндәгеләр күрсәтелә:

гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәлә; халык җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы – Югары Чура авылы җирлеге башкарма комитеты (алга таба – җирлек башкарма комитеты) турында мәгълүмат.

2.9. Авыл җирлеге башкарма комитеты авыл җирлеге башлыгы карары яки җирлек Советының Гражданнар җыенын үткәрү турындагы карары нигезендә сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләр исемлеген төзи; гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерли; муниципаль берәмлек халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итә (4 нче кушымта).

Авыл җирлеге Башкарма комитеты халык җыенын үткәрү өчен бина бирергә тиеш.

2.9.1. Гражданнар җыенын этаплап уздырганда, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү һәм халык җыенын үткәрү датасын территориаль, вакытлы билгеләр буенча, шулай ук башка очраклар буенча билгеләргә мөмкин.

2.9.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү тәртибен сайлау гражданнар җыенын билгеләү турында муниципаль актта күрсәтелә (5,6 нчы кушымталар).

2.9.3. Торак пунктта яшәүчеләргә гражданнар җыены (гражданнар җыены этаплары) вакыты һәм урыны турында алдан ук хәбәр ителә. Гражданнар җыенын (гражданнар җыены этапларын) билгеләү турында карар, гражданнар җыенын (гражданнар җыены этапларын) үткәрү вакыты һәм урыны гражданнар җыены (гражданнар җыены этапларын) үткәрелгән көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча басылып чыгарга тиеш. Гражданнар җыенының этапларын үткәрү вакыты һәм урыны бер карарда яисә гражданнар җыенын билгеләү турында карарда күрсәтелә.

2.9.4. Гражданнар җыенын этаплап уздырган очракта, гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакыт аралыгында җыен этаплап уздырыла. Халык җыены этапларын күчергәндә, Халык җыены этапларын күчерү турында карар җыенны уздыру билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча закон нигезендә җыен үткәрелергә тиешле айлык чорны исәпкә алып кабул ителергә тиеш.

2.9.5. Гражданнар җыенының һәр катнашучысы гражданнар җыенын үткәрү датасына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча муниципаль берәмлек органының әлеге нигезләмәнең 2.9 пунктында күрсәтелгән структур бүлекчәсендә гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышырга, шулай ук аларның күчермәләрен алырга хокуклы.

2.10. Гражданнар җыены турындагы Нигезләмә нигезендә, халык җыенын үткәрү датасы соңрак вакытка күчерелергә мөмкин. Халык җыенын уздыру датасын күчерү турында Карар билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

## 3. Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе

3.1. Җыенга килгән гражданнар торак пунктта яшәүчеләр исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучы кешеләрне теркәү өчен җирлек башлыгының вәкаләтле заты тарафыннан теркәлә. Исемлектә гражданнның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны, паспорт сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2. Җыенга җыенда катнашырга теләк белдергән башка гражданнар, җыенда күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итү аларның эшчәнлекләренә бәйле булган предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләре, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре дә хәлиткеч тавыш бирү хокукыннан башка кертелә.

3.3. Сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләр исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта, торак пунктта яшәүче кеше авыл җирлеге башлыгы тарафыннан теркәлергә һәм җыенында катнашырга мөмкин.

3.4. Язмаларның төгәлсезлегенә (яки аларның булмавына) раслау булып гражданинның шәхесен раслаучы документның булуы (Россия Федерациясе гражданины паспорты, хәрби билет, чит ил гражданы паспорты, Россия Федерациясендә яшәүгә рөхсәт, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт һәм башкалар) хезмәт итәргә мөмкин.

3.5. Гражданнар җыены анда сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы. Кворум булмаганда, халык җыенын үткәрүнең яңа датасын билгеләү җирлек башлыгы тарафыннан башкарыла. Бу очракта халык җыены халык җыенын үткәрү билгеләнгән көннән соң ун көннән дә иртәрәк үткәрелмәскә тиеш.

3.6. Гражданнар җыены этаплап уздырылган очракта, гражданнар җыены җыенның аерым этапларында гражданнар ничәү килсә дә хокуклы, аннан соң барлык уздырылган этаплар йомгаклары буенча тавышлар санала, ягъни мондый җыен бербөтен булып кала.

3.7. Гражданнар җыенында тавыш бирү ачык яисә яшерен булырга мөмкин. Тавыш бирү формасы турында карар гражданнар җыены тарафыннан кабул ителә.

3.8. Гражданнар җыенында катнашу өчен теркәлгән гражданга яшерен тавыш бирүне уздырганда тавыш бирү өчен бюллетень (7 нче кушымта) бирелә.

3.9. Гражданнар җыенында авыл җирлеге башлыгы яисә гражданнар җыенында теркәлгән катнашучылар саныннан гади күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын гражданнар җыенында катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.10. Гражданнар җыены сәркатибне һәм хисап комиссиясен сайлый. Хисап комиссиясе әгъзалары өч кешедән дә ким була алмый.

Хисап комиссиясенә рәислек итүче керә алмый.

Хисап комиссиясе:

1) гражданнар җыенына килгән торак пунутта яшәүче халыкның теркәлүенең дөреслеген, кирәк булган очракта, аларның халык җыенында катнашу хокуклары дөреслеген тикшерә;

2) гражданнар җыенының кворумын билгели (гражданнар җыены этапларын үткәрүдән тыш);

3) тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә;

4) тавышларны саный һәм тавыш бирүгә йомгак ясый (гражданнар җыены этапларын үткәрүдән тыш);

5) тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә төзи (гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча);

6) рәислек итүчегә тавыш бирү нәтиҗәләре белән материаллар (беркетмә, җыенда катнашучы гражданнар исемлеге) тапшыра.

3.11. Халык җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр рәислек итүче, җирлек башлыгы, гражданнар җыенында катнашу хокукына ия гражданнар тарафыннан кертелергә мөмкин. Көн тәртибенә халык җыенын чакыру инициаторлары тарафыннан кертелгән сораулар мәҗбүри рәвештә кертелә. Күрсәтелгән мәсьәләләр беренче чиратта карала. Халык җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләрне кертү турында карар, әгәр аның өчен җыенда катнашкан гражданнарның яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

3.12. Этаплап үткәрелгән гражданнар җыенында шулай ук авыл җирлеге башлыгы яисә гражданнар җыенында теркәлгән катнашучылар саныннан гади күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын гражданнар җыенында катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.13. Этаплап үткәрелгән гражданнар җыенында тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирү формасы турында карар гражданнар җыены этабында кабул ителә.

3.14. Гражданнар җыенын этаплап уздырганда, гражданнар җыены этапларының һәркайсында хисап комиссиясе арасыннан гражданнарның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча Хисап комиссиясенең кворумны һәм йомгаклау тавышларын санаганда комиссия составында эшләячәк берәр әгъзасы сайлана.

3.15. Җыен җыенда рәислек итүче тарафыннан ачыла. Гражданнар җыенында рәислек итүче гражданнар җыенын үткәрүне оештыра, тәртипне саклый, хисап комиссиясе эшен координацияли, фикер алыша торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, тавыш бирүнең билгеләнгән тәртибен тәэмин итә.

3.16. Гражданнар җыенында сәркатиб тарафыннан беркетмә алып барыла, анда гражданнар җыенын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, карала торган мәсьәләләр буенча тавыш биргән гражданнар саны (8 нче кушымта) күрсәтелә.

3.17. Халык җыенын этаплап уздырганда гражданнар җыенының һәр этабында беркетмәләр (9,10 нчы кушымталар) алып барыла, алар соңыннан халык җыенының уздырылган этаплары нәтиҗәләре буенча җыенның бер йомгаклау беркетмәсенә рәсмиләштерелә (11 нче кушымта), шулай ук Хисап комиссиясе беркетмәләренә (12,13 нче кушымталар) тутырыла, алар шулай ук гражданнар Җыенының һәр этабында тавышларны санау нәтиҗәләре буенча Хисап комиссиясенең бер йомгаклау беркетмәсенә (14 нче номерлы беркетмә) тутырыла.

3.18. Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсендә гражданнар җыены этапларының үткәрелү датасы, урыны һәм вакыты, көн тәртибе, гражданнар җыены этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны турында мәгълүматлар, гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча тавыш бирүнең йомгаклау нәтиҗәләре күрсәтелә. Йомгаклау беркетмәсе җирлек башлыгы кул куя торган һәм алга таба рәсми бастырып чыгарылачак (халыкка игълан ителәчәк) гражданнар җыены карарын рәсмиләштерү өчен нигез булып тора.

3.19. Беркетмә җыенда рәислек итүче зат, җыен секретаре тарафыннан имзалана һәм җирлек башлыгына тапшырыла. Беркетмәгә җыенда теркәлгән катнашучылар исемлеге беркетелә.

3.20. Гражданнар җыенының уздырылган этаплары йомгаклары буенча Хисап комиссиясенең йомгаклау беркетмәсендә гражданнар җыены этапларының үткәрелү датасы, урыны һәм вакыты, көн тәртибе, үткәрелгән җыен этапларының саны, үткәрелгән җыеннарның этаплары буенча Хисап комиссиясе беркетмәләре саны, җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче гражданнарның һәм җыен эшендә катнашырга хокуклы гражданнарның гомуми саны, җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны, РИЗА һәм КАРШЫ дип бирелгән тавышларның гомуми саны күрсәтелә.

3.21. Йомгаклау беркетмәсенә Хисап комиссиясе рәисе һәм Хисап комиссиясе әгъзалары кул куя һәм беркетмә җирлек башлыгына тапшырыла.

## 4. Гражданнар җыены карарлары

4.1. Гражданнар җыены карары, әгәр аның өчен җыенда сайлау хокукына ия булган катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып тора, җирлек башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары гражданнар, вәкаләтләрне чикләү нигезендә, җыенда кабул ителгән карарларның Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авылы җирлеге Уставы белән билгеләнгән үтәлешен тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар җыенда башка карар кабул итү юлы белән юкка чыгарылырга яки үзгәртелергә мөмкин яки суд тәртибендә гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин.

4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш һәм муниципаль хокукый актлар өчен таләпләр нигезендә рәсмиләштерелә.

4.6. Әгәр торак пунктта яшәүчеләрнең турыдан-туры үз теләкләрен белдерүе юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль хокукый акт кабул итү (басма) кирәк булса, әлеге актны кабул итү (бастырып чыгару) аларның компетенциясенә кергән җирле үзидарә органы һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи заты гражданнар җыенында кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән соң 15 көн эчендә тиешле муниципаль хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан да артмаска тиеш.

## Гражданнар җыены карарларын үтәү

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органнары, аларның вазыйфаи затлары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан раслауга мохтаҗ түгел.

4.8. Җыенда кабул ителгән карарларның үтәлмәве закон нигезендә җаваплылыкка тартыла.

**1 нче кушымта**
Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авылы җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә

ИМЗАЛАР КӘГАЗЕ

Без, түбәндә язылучылар, Кукмара муниципаль районы ____________________________ авылы җирлегенең ________________________ торак пунктында ____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________ соравы буенча гражданнар җыенын ________________________________ (гражданнар җыенын үткәрү вакыты) үткәрү инициативасын хуплыйбыз.

| № № п/п | Фамилия, исем, атасының исеме | Туган көне | Яшәү урыны адресы | Паспорт яки аны алмаштыручы документның сериясе һәм номеры | Имза куйган дата | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Имзалар кәгазен раслыйм _______________________________________________________
(имзалар җыючы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме,
____________________________________________________________________________________
туган көне, яшәү урыны, паспорт яки аны алмаштыручы документның сериясе һәм номеры)

_________________________________ ____________________ (имза һәм дата)

**Гражданнар җыенын инициатив төркем инициативасы белән чакырганда**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авылы җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә **Кушымта № 2**

**Карар**

**_______________ 20** ел** **№ ____**

**Кукмара муниципаль районы ________________________ авылы җирлегенең _____________________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы __________________________ авылы җирлеге Уставының … статьясы нигезендә _________________________ авылы җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 20** елның ______________________ 00 сәг. 00 минутка Кукмара муниципаль районы ___________________________авылы җирлегенең ___________________ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. 20** елның ______________________ 00 сәг. 00 минутка Кукмара муниципаль районы ___________________________авылы җирлегенең ___________________ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

« (үзара салым акчасы кертүдән азат булган гражданнар категорияләре күрсәтелә) затлардан кала, Кукмара муниципаль районы ____________________________ авылы җирлегенең ___________________ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 20_______ елда үзара салымны ___________ сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

… »

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы _____________________ авылы җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль

районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге
башлыгы урынбасары: А.Н. Афанасьев

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә
**Кушымта № 3**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**

**______________________ авылы җирлеге Башлыгы карары**

**_______________ 20** ел** **№ ____**

**«Кукмара муниципаль районы ______________________ авылы җирлегенең ____________________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы ________________________ авылы җирлеге Уставының … статьясы нигезендә

КАРАР ЧЫГАРАМ:

1. 20** елның ______________________ ______________ Кукмара муниципаль районы _________________________авылы җирлегенең __________________ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: ________________________ затлардан кала, Кукмара муниципаль районы __________________________ авылы җирлегенең __________________ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 20_______ елда үзара салымны ___________ сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

…

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып ___ көн эчендә мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге
башлыгы урынбасары: А.Н. Афанасьев

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә
**Кушымта № 4**

Кукмара муниципаль районы ________________________________ авылы җирлегендә сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр
ИСЕМЛЕГЕ

«______» _________________ 20___ ел

| №№ пп | Фамилия, исем, атасының исеме | Туган көне (18 яшьлекләрнең – туган көне, ае) | Яшәү урыны адресы | Паспорт сериясе, номеры | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ ______________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Гражданнар җыены сәркатибе _________ ______________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

**Гражданнар җыенын инициативалы төркем инициативасы белән чакырганда**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә **Кушымта № 2**

**Карар**

**_______________ 20** ел** **№ ____**

**Кукмара муниципаль районы ________________________ авылы җирлеге _____________________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы ___________________________ авылы җирлеге Уставының … статьясы нигезендә Кукмара муниципаль районы ___________________________ авылы җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

3. 20** елның ______________________ 00 сәг. 00 минутка Кукмара муниципаль районы _________________________авылы җирлегенең ___________________ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының беренче этабын** билгеләргә.

4. 20** елның ______________________ 00 сәг. 00 минутка Кукмара муниципаль районы _________________________авылы җирлегенең ___________________ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының икенче этабын** билгеләргә.

5. ***Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне (территориаль, вакытлыча яки башка билге буенча) сайлау тәртибе гражданнар җыенын билгеләү турындагы муниципаль актта күрсәтелә.***

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«(үзара салым акчасы кертүдән азат булган гражданнар категорияләре күрсәтелә) затлардан кала, Кукмара муниципаль районы ________________________________ авылы җирлегенең _____________________ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 20_______ елда үзара салымны ___________ сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

………… »

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге
башлыгы урынбасары: А.Н. Афанасьев

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыены турында Нигезләмәгә **Кушымта № 6**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**

**_______________________ авылы җирлеге Башлыгы карары**

**________________ 20** ел** **№ ____**

**«Кукмара муниципаль районы ________________________ авылы җирлеге _____________________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы ___________________________ авылы җирлеге Уставының … статьясы нигезендә

КАРАР ЧЫГАРАМ:

1. 20** елның ______________________ 00 сәг. 00 минутка Кукмара муниципаль районы _________________________авылы җирлегенең ___________________ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының беренче этабын** билгеләргә.

2. 20** елның ______________________ 00 сәг. 00 минутка Кукмара муниципаль районы _________________________авылы җирлегенең ___________________ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының икенче этабын** билгеләргә.

3. ***Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне (территориаль, вакытлыча яки башка билге буенча) сайлау тәртибе гражданнар җыенын билгеләү турындагы муниципаль актта күрсәтелә.***

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

_____________ затлардан кала, Кукмара муниципаль районы ______________________________ авылы җирлегенең ____________________ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 20_______ елда үзара салымны ____________ сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

………… »

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә мәгълүмати стендлар һәм җирлекнең рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы бел халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге
башлыгы урынбасары: А.Н. Афанасьев

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авылы җирлеге составына керүче _____торак пунктта гражданнар җыены турында Нигезләмәгә **Кушымта № 7**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы ________________________ авылы җирлеге составына керүче ___________________________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча яшерен тавыш бирү**

**БЮЛЛЕТЕНЕ**

| | | |
|---|---|---|
| Яшерен тавышка куелган мәсьәләнең эчтәлеге | «ӘЙЕ» | ☐ |
| | «ЮК» | ☐ |
| | | |

Татарстан Республикасы Кукмара муниципа
районы Югары Чура  җирлеге составына кер
торак пунктларда гражданнар җыены турынд
Нигезләмәгә **Кушымта № 8**

**Гражданнар җыены беркетмәсе**

_______________________________________________

(торак пунктның исеме)

«___» ____________ 20_____ ел    00 сәг. 00 минут                    № _____

Катнаштылар _________________________________________________ кеше

(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында рәислек итүче____________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

Гражданнар җыены сәркатибе __________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

**Көн тәртибе:**

1.

2.

**ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА:**

1. ____________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазыйфасы)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:     «Риза» – ____ кеше
«Каршы» – _____ кеше

**ҖЫЕН СӘРКАТИБЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** җыенның сәркатибен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак?

Җыен сәркатибе итеп <u>ФИО, вазыйфасы</u> сайлау тәкъдиме дә бар

Тавыш бирү нәтиҗәләре:     «Риза» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

**ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** гражданнар җыенының кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп ___________ФИО һәм хисап комиссиясе әгъзаларын сайлау тәкъдиме дә бар:

1. ___________ -
2. ____________ –

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Риза» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

## КӨН ТӘРТИБЕНДӘГЕ МӘСЬӘЛӘ БУЕНЧА ТАВЫШ БИРҮ ТӘРТИБЕ БИЛГЕЛӘНӘ:

**Рәислек итүче:** көн тәртибендәге мәсьәлә буенча тавыш бирү формасын билгеләргә кирәк. Тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирүне уздыру формасы турында тәкъдим залга әйтелә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Риза» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

**Көн тәртибе буенча эш:**

**Беренче сорау буенча тыңладылар:**
______________________________________________________________________
(фамилия, исеме, этисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________________
(фамилия, исеме, этисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә) һ.б. (чыгыш ясаучы гражданнар санынча)

**Карар чыгардылар:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Риза» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

Карар _________________________
кабул ителгән (кабул ителмәгән)

**Икенче сорау буенча тыңладылар:**
______________________________________________________________________
(фамилия, исеме, этисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________________
(фамилия, исеме, этисенең исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә) һ.б. (чыгыш ясаучы гражданнар санынча)

**Карар чыгардылар:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Әйе» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

Карар ___________________________________
кабул ителгән (кабул ителмәгән)

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ ______________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)
Гражданнар җыены сәркатибе _________ ________________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

**Гражданнар җыенын этаплап**
**үткәргән очракта**

Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы Югары Чура
авылы җирлеге составына керүче торак
пунктларда гражданнар җыены турында
Нигезләмәгә **Кушымта № 9**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЭТАБЫ БЕРКЕТМӘСЕ**

___________________________________________________

(торак пунктның исеме)

«___» ____________ 20____ ел 00 сәг. 00 минут № __1___

Катнаштылар ________________________________________________ кеше
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында рәислек итүче________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
Гражданнар җыены сәркатибе ____________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

**Көн тәртибе:**
1.
2.

**ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА:**

_______________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазыйфасы)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Риза» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

**ҖЫЕН СӘРКАТИБЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** җыенның сәркатибен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак?

Җыен сәркатибе итеп ФИО, вазыйфасы сайлау тәкъдиме дә бар.

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Риза» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

**ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** гражданнар җыенының кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп ____________ФИО һәм хисап комиссиясе әгъзаларын сайлау тәкъдиме дә бар:

3. ___________ -
4. ___________ –
һ.б.

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Риза» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

## КӨН ТӘРТИБЕНДӘГЕ МӘСЬӘЛӘ БУЕНЧА ТАВЫШ БИРҮ ТӘРТИБЕ БИЛГЕЛӘНӘ:

**Рәислек итүче:** көн тәртибендәге мәсьәлә буенча тавыш бирү формасын билгеләргә кирәк. Тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирүне уздыру формасы турында тәкъдим залга әйтелә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Риза» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

**Көн тәртибе буенча эш:**

**Беренче сорау буенча тыңладылар:**

______________________________________________________________

(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. _____________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә) һ.б. (чыгыш ясаучы гражданнар санынча)

**Карар чыгардылар:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Риза» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

**Икенче сорау буенча тыңладылар:**

______________________________________________________________

(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. _____________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә) һ.б. (чыгыш ясаучы гражданнар санынча)

**Карар чыгардылар:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Әйе» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

**Рәислек итүче: йомгаклау карарының нәтиҗәсе ______________________ авылы җирлеге Уставы нигезендә гражданнар җыенының уздырылган этапларының тавышларын санау нәтиҗәләре буенча рәсми рәвештә басылып чыгачак (игълан ителәчәк).**

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ ________________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)
Гражданнар җыены сәркатибе _________ ________________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

**Гражданнар җыенын этаплап**
**үткәргән очракта**

Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы Югары Чура
авылы җирлеге составына керүче торак
пунктларда гражданнар җыены турында
Нигезләмәгә **Кушымта № 10**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЭТАБЫ БЕРКЕТМӘСЕ (һ.б.)**

________________________________________________

(торак пунктның исеме)

«___» ____________ 20__ ел 00 сәг. 00 минут № __2___

Катнаштылар ________________________________________________ кеше
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында рәислек итүче______________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

Гражданнар җыены сәркатибе ______________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

**Көн тәртибе:**

1.
2.

**ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА:**

________________________________________________

________________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазыйфасы)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Риза» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

**ҖЫЕН СӘРКАТИБЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** җыенның сәркатибен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак?

Җыен сәркатибе итеп ФИО, вазыйфасы сайлау тәкъдиме дә бар.

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Риза» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

**ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** гражданнар җыенының кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен Хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп ___________ФИО һәм хисап комиссиясе әгъзаларын сайлау тәкъдиме дә бар:

5. ___________ -
6. ____________ –
һ.б.

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Риза» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

**КӨН ТӘРТИБЕНДӘГЕ МӘСЬӘЛӘ БУЕНЧА ТАВЫШ БИРҮ ТӘРТИБЕ БИЛГЕЛӘНӘ:**

**Рәислек итүче:** көн тәртибендәге мәсьәлә буенча тавыш бирү формасын билгеләргә кирәк. Тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирүне уздыру формасы турында тәкъдим залга әйтелә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Риза» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

**Көн тәртибе буенча эш:**

**Беренче сорау буенча тыңладылар:**
_______________________________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ____________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә) һ.б. (чыгыш ясаучы гражданнар санынча)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Риза» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

**Икенче сорау буенча тыңладылар:**
_______________________________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ____________________________________________
(фамилия, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә) һ.б. (чыгыш ясаучы гражданнар санынча)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Әйе» – ____ кеше
«Каршы» – ____ кеше

**Рәислек итүче: йомгаклау карарының нәтиҗәсе ______________________ авылы җирлеге Уставы нигезендә гражданнар җыенының уздырылган этапларының тавышларын санау нәтиҗәләре буенча рәсми рәвештә басылып чыгачак (игълан ителәчәк).**

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ ________________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Гражданнар җыены сәркатибе _________ ___________________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы Югары Чура авылы җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыены турында Нигезләмәгә **Кушымта № 11**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ УЗДЫРЫЛГАН ЭТАПЛАРЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА ҖЫЕННЫҢ ЙОМГАКЛАУ ПРОТОКОЛЫ**

______________________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы ______________муниципаль районы___________ торак пунктның исеме)

«____»_____________ 20______ ел 00 сәг. 00 минут № ____

Гражданнар җыенының 20____ елның _________________________ уздырылган беренче этабының (рәислек итүче ФИО) 1 нче номерлы беркетмәсе, 20____ елның __________________ уздырылган икенче этабының (рәислек итүче ФИО) 2 нче номерлы беркетмәсе һ. б. нигезендә, ______________________________
______________________________________________________________________________
соравы (-лар) буенча этаплап гражданнар җыеннары уздырылды.

1.Җыенның үткәрелгән этаплары саны, тавыш бирү формасы күрсәтелә (ачык яки ябык (яшерен)_______
2. Этаплап уздырылган гражданнар җыеннарының тапшырылган беркетмәләре саны ______
3. Җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм аның эшендә катнашырга хокукы булган гражданнарның гомуми саны __________;
4. Сайлау хокукына ия һәм гражданнар җыены этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны ___________

**Карар чыгарылды: (карарның эчтәлеге)**

- Гражданнар җыены этапларында кертелгән мәсьәлә (-ләр) өчен «РИЗА» булып бирелгән тавышларның гомуми саны _________;
- Кертелгән мәсьәләгә (мәсьәләләргә) «КАРШЫ» бирелгән тавышларның гомуми саны)

**КАРАР: кабул ителде (кабул ителмәде, сәбәпләре күрсәтелә)**
Рәислек итүче (җирлек Башлыгы) _________ ______________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)
Сәркатиб _________ ______________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Кукмара муниципа
районы
Югары Чура җирлеге составына керүче тора
пунктларда гражданнар җыены турында
Нигезләмәгә
**Кушымта № 12**

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЭТАБЫ ХИСАП КОМИССИЯСЕ ПРОТОКОЛЫ

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы ________________ авылы җирлеге состав керүче _______________________ торак пунктында тавыш бирү нәтиҗәләре турында

«_____» ______________ 2019 ел № 1

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы ________________ авылы җирлеге торак пункты исеме

**Катнашалар**: Хисап комиссиясе әгъзалары:

1. ФИО;
2. ФИО;
3. ФИО;

һ.б.

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган _______граждан катнаша (- ты).

Гражданнар җыенының беренче этабындагы көн тәртибе мәсьәләсе буенча тавыш б нәтиҗәләре:

«___________________________________________________________________________________»

**«РИЗА»______________тавыш**

**«КАРШЫ»__________тавыш**

Хисап комиссиясе рәисе: ФИО

Хисап комиссиясе әгъзалары: ФИО

ФИО

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Югары Чура җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыены турында Нигезләмәгә
**Кушымта № 13**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ ИКЕНЧЕ ЭТАБЫ ХИСАП КОМИССИЯСЕ ПРОТОКОЛЫ

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы ________________ җирлеге составына керүче ______________________ торак пунктында тавыш бирү нәтиҗәләре турында

«_____» ________________ 2019 ел

№ 2

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы ________________ авылы җирлеге торак пункты исеме

**Катнашалар**: Хисап комиссиясе әгъзалары:

1. ФИО;
2. ФИО;
3. ФИО;

һ.б.

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган _______граждан катнаша (- ты).

Гражданнар җыенының икенче этабындагы көн тәртибе мәсьәләсе буенча тавыш бирү нәтиҗәләре:

«_____________________________________________________________________________»

**«РИЗА»_______________тавыш**

**«КАРШЫ»__________тавыш**

Хисап комиссиясе рәисе ФИО

Хисап комиссиясе әгъзалары: ФИО

ФИО

Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы Югары Чура
авылы җирлеге составына керүче торак
пунктларда гражданнар җыены турында
Нигезләмәгә **Кушымта № 14**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**__________________________ авылы җирлеге гражданнары җыенының**
(торак пункт исеме)
**беренче, икенче (һ.б.) этаплары нәтиҗәләре буенча тавыш бирү йомгаклары (нәтиҗәләре) турында**
**ХИСАП КОМИССИЯСЕ БЕРКЕТМӘСЕ**

20__ елның «____» _________________ ______________________________________
(торак пункт исеме)
___________________________________________________________________________
(муниципаль берәмлек территориясе
___________________________________________________________________________
яисә аның өлеше исеме)
территориясендә гражданнар җыенының беренче, икенче (һ. б.) этапларында тавыш бирү нәтиҗәләре
Гражданнар җыенының этапларын үткәрү датасы һәм вакыты:
________________ __________________________ 20__ ел

Гражданнар җыеннарында _________________________________________________
___________________________________________________________________________
соравы (сораулары) буенча тавыш биргәндәге тавышларны санау нәтиҗәсендә

**Хисап комиссиясе билгеләде:**

1. 1. Халык җыенының үткәрелгән этаплары саны ____________________________;
2. Үткәрелгән гражданнар җыены этапларының Хисап комиссиясе тәкъдим иткән беркетмәләрнең саны ___________________________________________________;
3. Җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм җыен эшендә катнашырга хокукы булган гражданнарның гомуми саны ____________________;
4. Җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны ____________________;
5. Гражданнар җыенына кертелгән мәсьәлә (-ләр) өчен «РИЗА» булып бирелгән тавышларның гомуми саны ________________________________________;
6. - Кертелгән мәсьәләгә (мәсьәләләргә) «КАРШЫ» бирелгән тавышларның гомуми саны) ___________________________________________________________ .

**Карар чыгарылды:**

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә ______________________________________ мәсьәләсе буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга, __________________________________________ соравы буенча җыен карары кабул ителгән дип санарга.

Хисап комиссиясе рәисе ______________________________ ________________
(фамилиясе, инициаллары) (имза)

Хисап комиссиясе әгъзалары 1. ___________________________ ________________
(фамилиясе, инициаллары) (имза)

2. _____________________________________ ________________
(фамилиясе, инициаллары) (имза)

Беркетмә төзелде: «___» ______________ 20___ ел